Изге Китабыбыз

# Еш укылган Коръән сүрәләре

## «Шәһру Рамазан» аятьләре

Коръән уку культурасында тәүлек вакытына, үткәрелгән мәрасимгә (чара) яисә барган заманга (һиҗри календарь буенча) карап, туры китереп, өзекләрне сайлап уку гадәте бар. Шундый урынвакытка нисбәтле буларак укылган Коръән өлешләреннән дә "Шәһру Рамазан" һәм "Иннә әнзәлнаһ" өзекләрен әйтеп була. Беренчесенең исеменнән дә аңлашылганча, болар Рамазан аенда мәчеттә яки өйдә ифтар (авыз ачу) мәҗлесләрендә укыла. Бу өзекләрнең беренчесе, озынрак булганы, үзенең исемен шушы өзектә булган бер аятьнең беренче сүзләреннән алган. Бу гадәти һәм сөннәт булган бер нәрсә. Ягъни Пәйгамбәребез үзе дә, әйтик, "Ихлас" сүрәсен - "Куль һуваллаһу әхәд", "Зилзаль" сүрәсен - "Изә зүлилӛтил әрзу", «Фәләк» сүрәсен "Куль әгузу бираббиннәс" дип атый торган булган.

"Шәһру Рамазан" дип йөртелгән өзекне шушы исемгә сәбәпче булган "Шәһру Рамазан" сүзләре белән башланган аятеннән алып (башлап) укылган шикелле бер аять тә алданрак, ягъни *"Йә әййүһәлләзинә әммәну, күтибә галәйкум.."* аятеннән башлап уку да бар. Без дә шушы югарырак, алдарак булган аятьтән аңлатуны урынлы күрдек. Без Коръәннең оригиналын, ягъни гарәпчә язылышын газетабызда бастырмаска булдык, чөнки газетаны төрле халәттәге төрле кеше куллануы мөмкин. Ә билгеле булганча, Коръәнне тәһарәтле килеш кенә тоту рөхсәт ителә. Шуңа күрә иң беренче бу өзекнең хәзерге хәрефләр белән транскрипциясен бирәбез.

### "Шәһру Рамазан"ның укылышы

Йәәә әййүһәлләзиинә әәмәнуу күтибә галәйкумус-сыйәәму кәмәә күтибәлләзиинә миң кабликум ләгалләкум тәттәкун. Әййәәмәммәгдуудәәт. Фәмәң кәәннә миңкум мәриидан әу галәә сәфәриң фәгыйддәтум мин әййәәмин ухар. Вә галәлләзиинә йутыйкуунәһум фидйәтүң тагааму мискиин. Фәмәң тәтаувәга хайраң фәһувә хайруль-ләһ. Вә әң тәсууму хайруль ләкум иң күңтум тәгьләмуун.

Шәһру рамәдаанәлләзии үңзилә фиһилКурьәанү һүдәллин-нәәәси үә бәййинәәтим-минәлһүдәә үәл-фуркаан. Фәмәң шәһидә миңкүмүшшәһра фәл-йәсумһ. Вә мәң кәәнә мәриидан әү галәә сәфәриң фәгыйддәтүм-мин әййәәмин ухар. Йүриидуллааһу бикүмүл-йүсра үә ләә йүриидү бикүмүл-гүсра үә литүкмилүл-гыйддәтә үә литүкәббируллааһә галәә мәә һәдәәкүм үә ләгальләкүм тәшкурууун.

Үә изәә сә'әләкә гыйбәәди ганнии фә иннии карииб! Уҗиибү дәгъүәтәд-дәәәгый изәәә дәгани фәл-йәстәҗиибу лии үәл-йүәминуу бии ләгальләһүм йәршүдүүн.

### "Шәһру Рамазан"ның тәрҗемәсе

Тәрҗемәгә килсәк, бу өзекнең мәгънәсе түбәндәгечә:

"Ий, иман китереп ышанучылар! Сезнең өстегезгә нәкъ сездән элек булган (халыклар)ның өстендә шикелле ураза тоту йөкләнелде. Бәлки, (шул билгеле көннәрдә ураза тотуыгыз аркасында) сез тәкъвалык изләреннән булырсыз (дип). Араларыгыздан кем дә булса авыру яки сәфәрдә (юлда) булса, башка көннәрдә ураза тотар. Ураза тоталмаганнарга исә, әгәр хәлләреннән килсә, фидиясе (тота алмаган уразa көненең каршылыгы булган бәһа) - мескенне ашату. Кем дә булса үз теләге белән бер хәерлек (яхшылык) эшләсә, үзе өчен хәерле булыр. Ураза тоту үзегез өчен хәерле булганын белсәгез иде!

Рамазан ае шундый ай ки, кешеләргә, җитәкчелек, туры юл һәм аергыч аңлатмалары буларак, Коръән иңгән айдыр. Бу айны исән-сау каршы алган кеше ураза тотсын. Кем дә булса авыраса яки мосафир булса, (тота алмаган көннәр) саны буенча башка көннәрдә тотсын. Аллаһы сезгә җиңеллек тели һәм сезгә авырлык теләмәс, һәм (Рамазан аеның) көннәр санын тулысынча тутыруыгызны, һәм Аллаһы үзегезне туры юлга күндергәнгә, Аны тәкбирләр илә олылар өчен! Бәлки, сез шөкер итүегезне (рәхмәтегезне) белдерерсез!

«(Ий Пәйгамбәрем Мөхәммәд!) Әгәр бәндәләрем синнән Минем турыда сорасалар, Мин, хакыйкатьтә, аларга якын бит. Миңа дога кылып үтенүченең догасына җавап бирермен (кабул итәрмен). Шуңа күрә алар да Миңа (кушканнарымны үтәп) җавап кайтарсыннар һәм Миңа ышансыннар! Бәлки, туры юлга басарлар". («Әл-Бәкара», 183-184 аятьләр.)

### Коръәннең бу өлешен ни өчен укыйбыз?

Бу аятьләрдә Рамазан ае, бу айда ураза тоту турында сөйләнелгәнгә, алар ифтарларда (авыз ачу мәҗлесләрендә), Рамазан аенда мәчетләрдә намаздан соң, Коръән уку вакытында яки башка үткәрелгән дини чараларда укылып килә.

### Бу аятьләрдән нәрсә аңлыйбыз?

Коръәни-Кәримдә исеме белән аталган айлар саны бик аз. Шулар арасында Рамазан ае булуы бу айның аерым урын-дәрәҗәгә ия булуын күрсәтә. Рамазан ае турында сөекле Пәйгамбәребезнең хәдисләрендә дә бик күп сөйләнелә. Һәм бу айның үзенчәлекләре турында без мәгълүматны иң күбе шул хәдисләрдән алабыз да инде.

"Шәһру Рамазан" өзегенең беренче аятеннән без Аллаһы Тәгаләнең уразаны ни өчен тотарга кушканын беләбез - кешеләрдә тәкъвалык дигән нәрсә барлыкка килсен, ә булганнарда - бу тәкъвалыклары артсын өчен.

Икенче аятеннән без ураза тоту вакыты буларак Аллаһы Тәгаләнең нинди вакытны билгеләгәнен беләбез. Ул һиҗри календарьның Рамазан ае икән, һәм Аллаһы тотарга кушкан фарыз ураза бары тик Рамазан аенда гына тотыла, ягъни ураза буларак бу айны бары тик фарыз ураза тоту өчен генә кулланып була. Фикһый (Ислам юриспруденциясе) яктан сөйләгәндә, Рамазан аенда тотылган ураза ничек кенә ният ителмәсен, әйтик, кеше хаталанып яки үз теләге белән «нәзер» (яки "нәфел") уразасын тотарга ниятләсә дә, тоткан уразасы бары тик фарыз ураза буларак кына саналачак.

"Шәһру Рамазан" сүзләре белән башланган аятьтән исә без ураза тоту өчен ник Рамазан ае билгеләнгәнен белә алабыз. Чөнки бу айда Җир йөзенә беренче мәртәбә Коръән иңә башлаган. Димәк, Аллаһы Тәгалә мөбарәк Китабы Коръәни-Кәримне хөрмәт итеп, колларының игътибарын шул Китапка юнәлтер, аңа хөрмәт уятыр өчен ураза тотуны шушы вакытка туры китергән.

Борынгы дини әсәрләрдә Аллаһы Тәгаләнең "Рамазан" кебек исеме дә барлыгы турындагы риваятьләр очрый. Шуның өстенә, сөекле Пәйгамбәребез (саллаллаһу галәйһи вә сәлләм): «Сез бу айга "Рамазан" гына димәгез, ә хөрмәт итеп "Рамазан ае" дип әйтегез!» дигән. Шулай итеп, Рамазан ае Коръән иңә башлаган ай булу өстенә, Аллаһы Тәгаләнең исемнәреннән бер исеме дә булгач, аны аерым хөрмәт итү тиеш була. Рәсүлебез бу айның кадерлелеген аңлатып хәдисләрендә:

"Рамазан — мөбарәк бер ай, бу айда җәннәт капкалары ачылыр, ә җәһәннәмнең капкалары ябылыр һәм шайтаннар богауланыр", "Рамазан аеннан (бу айда гөнаһ эшләүдән) куркыгыз. Унбер айны Аллаһы Тәгалә сезгә ашарга, эчәргә, ләззәтләнергә булдырган, Үзенә исә бер айны калдырган. Куркыгыз Рамазан аеннан — ул Аллаһы Тәгаләнең аедыр», «Айларның әфәндесе (өстене, хуҗасы) — Рамазан аедыр, хөрмәт ягыннан иң бөеге — Зөлхиҗҗә аедыр», — дип әйткән.

Бу аятьтән Рамазан аен туры китергән, ягъни тормыш барышында бу айга туры килгән кешенең аны ураза тотып үткәрергә тиешлеге аңлашыла. Тик "күркәм исемнәренең" күбесендә "мәрхәмәтле, миһербанлы, шәфкатьле, йомшак күңелле, кайгыртучан" сыйфаты булган һәм колларының хәлен бик яхшы белгән Раббыбыз Аллаһы Тәбарәкә һәм Тәгалә тик кушып, боерып кына калмый, бу эшнең искәрмәләрен дә аңлатып китә. Әйтик, нинди очракларда нинди хәлдәге кешеләргә уразаны тотмаска рөхсәт ителгәнен һәм тота алмауның нәтиҗәсен - фидия түләргә кирәклеген дә ачыклый.

### Аятьләрдән чыгарылган хөкем һәм нәтиҗәләр:

1) Аллаһының бер әмере, кушуы һәм Ислам диненең терәге булган уразаны үтәү - мөселман өстендәге бер җаваплы вазыйфа,

2) ураза тотудан максат итеп Аллаһы Тәгалә кешеләрнең тәкъвалыгын арттыруны куйган,

3) фарыз ураза бары тик Рамазан аенда һәм билгеле көннәрдә генә тотыла,

4) авырган һәм сәфәрдә булган кешеләр уразаларын тотмыйча, казага (ягъни соңыннан, башка вакытта үтәргә) дип калдыра алалар,

5) каза уразасы тулы итеп башкарылырга, ягъни ничә көн ураза тотылмыйча калган булса, шул хәтле көн ураза да тотылырга тиешле,

6) Рамазан аенда кешенең хәерле эше үзенә хәерле эш булып кайтыр,

7) авыру яки сәфәрдә булуына карамастан, уразасын тоткан кешеләргә һәм боерылган уразаны тотучыларның барысына да тоткан уразалары бер хәер-яхшылык булыр,

8) Үзе бар иткән колларының халәтләрен (тота алачакларын) белгән Аллаһы Тәгалә уразаны бер авырлык итеп бар итмәгән. Һәм, нигездә, авыр булмаган бу уразаны теге яки бу сәбәпләрдән (авырыу, юлда булу һ.б.) барыбер тотуны авырсынган кешеләргә исә башка вакытта тотарга рөхсәт бирелгән,

9) ураза - бер шөкер итү (кеше өчен бар иткән исәпсез нигъмәтләре өчен аларның хакыйкый хуҗасы булган Аллаһыга рәхмәт әйтү) юлы,

10) ураза - аны тотучы кешене Раббысына якынайта һәм нәтиҗәдә догасының кабул булуын тәэмин итә торган бер чара,

11) мөселман берәр теләге булганда, бу теләгенә ирешер өчен, Аллаһыга дога кылырга, ягъни үтенү белән чын күңелдән мөрәҗәгать итәргә тиеш,

12) без, кешеләр, Изге Китабыбыз Коръәни-Кәримне хөрмәт итәргә һәм, үзебезгә барыр өчен туры юл буларак, аның кануннарын һәм хөкемнәрен алырга тиешле. Чөнки Коръәни-Кәрим шул «туры юлны күрсәтер» һәм кеше кулланган аш-суда, кием-салымда, кирәк-яракта, хәрәкәтләрдә, уй-фикер, гыйлем-мәгърифәт һәм башкалар өлкәләрдә «аергыч» (кайсыларын куллану рөхсәт, урынлы, хәләл, ә кайсыларын куллану зарарлы, уңайсыз, хәрәм икәнлеген аңлаткан кулланма) буларак һәм кешеләрне бәхетле итәр, һәм сөендерер өчен иңдерелгән.

Йомгаклап бу аятьләр хакында шуны әйтеп була. "Шәһру Рамазан" өзеге уразаның мәҗбүрилеге, тоту тәртибе һәм кагыйдәләре, кемгә ураза тоту тиешле, кемгә тиешсез, фидия бирү ничек һәм күпме булырга, ничә көн буена ураза тотылырга, Рамазан аенда уразаның кайсы төрләрен (фарыз, нәфел, нәзер) тоту ярыймы һәм шундый башка төрле мәсьәләләрне ачыкларга мөмкинлек бирә.

**Иршат хәзрәт САФИН әзерләде.**